РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабрь 2019 ел Олы Кайбыч ав. № 206

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган үзагачны сату кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында һәм дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сатуны оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2019елның 17 октябрендәге 1341 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 184 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.2. 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

6.2.1., 6.2.22.,6.5. пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы мөлкәтне сату функцияләрен мөстәкыйль гамәлгә ашыра, шулай ук үз карарлары белән «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 8_1 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга милекче исеменнән муниципаль берәмлекләр милкендәге хосусыйлаштырыла торган милекне билгеләнгән тәртиптә сатуны һәм (яисә) мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыруны йөкли.»;

9.3 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү дигәндә хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматтан затларның чикләнмәгән

даирәсеннән ирекле файдалана алу мөмкинлеген булдыруга юнәлдерелгән һәм «Интернет» челтәрендә мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планының (программасының) рәсми сайтында, мөлкәтне хосусыйлаштыруны планлаштыру актларын, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарларны, муниципаль мөлкәтне сату турында һәм аны сату йомгаклары турында мәгълүмати хәбәрләрне, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында еллык хисапларны урнаштыруны үз эченә алган чаралар аңлашыла.»;

9.3 пунктының 16 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 78-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 8_1 пунктчасы нигезендә муниципаль мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыра һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының карарлары нигезендә хосусыйлаштырыла торган муниципаль мөлкәтне сатуны милекче исеменнән оештыруны йөкләнгән юридик затка түләү күләме һәм тәртибе.»;

12.1., 12.2. пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Акцияләре Кайбыч муниципаль районы милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең хокуклары муниципаль берәмлек исеменнән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла. ».

«12.2. Муниципаль милектә акционер җәмгыятьләр акцияләренең 100 проценты булса, җәмгыять идарәсенең югары органы - акционерларның гомуми җыелышы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы милекчесе исеменнән гамәлгә ашырыла. «Акционерлар җәмгыятьләре турында» Федераль закон белән каралган акционерларның гомуми җыелышын әзерләү һәм уздыру процедуралары кулланылмый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы урынбасары Хәялиев Р.Р.ка йөкләргә.

Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин